КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2023 ел, 31 октябрь г.Казань № 1383

Балигъ булмаган затларга һәм суд тарафыннан хокуктан файдалануга сәләтсез яисә хокуктан файдалану сәләте чикләнгән дип танылган затларга карата опека һәм попечительлек эшчәнлеген оештыру һәм гамәлгә ашыру буенча Татарстан Республикасы дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыручы хезмәткәрләрнең норматив саны турында

«Татарстан Республикасында муниципаль берәмлекләрнең җирле үзидарә органнарына опека һәм попечительлек өлкәсендә Татарстан Республикасының аерым дәүләт вәкаләтләрен бирү турында» 2008 елның 20 мартындагы 7-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законын гамәлгә ашыру максатларында Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Опека һәм попечительлек эшчәнлеген оештыру һәм гамәлгә ашыру буенча Татарстан Республикасы дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыручы хезмәткәрләрнең норматив санын түбәндәгечә билгеләргә:

балигъ булмаган затларга карата – җирле үзидарә органнары тарафыннан балигъ булмаган затларга карата опека һәм попечительлек эшчәнлеген оештыру һәм гамәлгә ашыру буенча Татарстан Республикасы дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыру өчен Татарстан Республикасы бюджетыннан муниципаль районнар һәм шәһәр округлары бюджетларына бирелә торган субвенцияләр күләмен билгеләү өчен кулланыла торган норматив санын 154 кеше күләмендә;

суд тарафыннан хокуктан файдалануга сәләтсез яисә хокуктан файдалану сәләте чикләнгән дип танылган затларга карата – җирле үзидарә органнары тарафыннан суд тарафыннан хокуктан файдалануга сәләтсез яисә хокуктан файдалану сәләте чикләнгән дип танылган затларга карата опека һәм попечительлек эшчәнлеген оештыру һәм гамәлгә ашыру буенча Татарстан Республикасы дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыру өчен Татарстан Республикасы бюджетыннан

муниципаль районнар һәм шәһәр округлары бюджетларына бирелә торган субвенцияләр күләмен билгеләү өчен кулланыла торган норматив санын 57 кеше күләмендә;

2. Бу карарга расланган Балигъ булмаган затларга һәм суд тарафыннан хокуктан файдалануга сәләтсез яисә хокуктан файдалану сәләте чикләнгән дип танылган затларга карата опека һәм попечительлек эшчәнлеген оештыру һәм гамәлгә ашыру буенча Татарстан Республикасы дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыручы хезмәткәрләрнең норматив саны бүленешен расларга.

2. Бу карар, 2024 елга, 2025 һәм 2026 еллар план чорына Татарстан Республикасы бюджетыннан башлап, Татарстан Республикасы бюджетын төзегәндә һәм үтәгәндә барлыкка килә торган хокук мөнәсәбәтләренә карата кулланыла дип билгеләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин

Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2023 ел, 9 октябрь, 1269 нчы
карары белән расланды

Балигъ булмаган затларга һәм суд тарафыннан хокуктан файдалануга сәләтсез яисә хокуктан файдалану сәләте чикләнгән дип танылган затларга карата опека һәм попечительлек эшчәнлеген оештыру һәм гамәлгә ашыру буенча Татарстан Республикасы дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыручы хезмәткәрләрнең норматив саны бүленеше

(кеше)

| Муниципаль район (шәһәр округы) исеме | Барысы | Шул исәптән | |
|---|---|---|---|
| | | балигъ булмаган затларга карата | суд тарафыннан хокуктан файдалануга сәләтсез яисә хокуктан файдалану сәләте чикләнгән дип танылган затларга карата |
| 1 | 2 | 3 | 4 |
| Әгерҗе муниципаль районы | 3 | 2 | 1 |
| Азнакай муниципаль районы | 3 | 2 | 1 |
| Аксубай муниципаль районы | 3 | 2 | 1 |
| Актаныш муниципаль районы | 3 | 2 | 1 |
| Алексеевск муниципаль районы | 3 | 2 | 1 |
| Әлки муниципаль районы | 3 | 2 | 1 |
| Әлмәт муниципаль районы | 7 | 6 | 1 |
| Апас муниципаль районы | 3 | 2 | 1 |
| Арча муниципаль районы | 3 | 2 | 1 |
| Әтнә муниципаль районы | 2 | 1 | 1 |
| Баулы муниципаль районы | 3 | 2 | 1 |
| Балтач муниципаль районы | 3 | 2 | 1 |
| Бөгелмә муниципаль районы | 4 | 3 | 1 |
| Буа муниципаль районы | 3 | 2 | 1 |
| Югары Ослан муниципаль районы | 3 | 2 | 1 |
| Биектау муниципаль районы | 3 | 2 | 1 |
| Чүпрәле муниципаль районы | 3 | 2 | 1 |
| Алабуга муниципаль районы | 5 | 4 | 1 |
| Зәй муниципаль районы | 3 | 2 | 1 |
| Зеленодольск муниципаль районы | 7 | 6 | 1 |
| Кайбыч муниципаль районы | 2 | 1 | 1 |
| Кама Тамагы муниципаль районы | 2 | 1 | 1 |
| Кукмара муниципаль районы | 3 | 2 | 1 |
| Лаеш муниципаль районы | 3 | 2 | 1 |
| Лениногорск муниципаль районы | 4 | 3 | 1 |

| 1 | 2 | 3 | 4 |
|---|---|---|---|
| Мамадыш муниципаль районы | 3 | 2 | 1 |
| Менделеевск муниципаль районы | 3 | 2 | 1 |
| Минзәлә муниципаль районы | 3 | 2 | 1 |
| Мөслим муниципаль районы | 3 | 2 | 1 |
| Түбән Кама муниципаль районы | 9 | 8 | 1 |
| Яңа Чишмә муниципаль районы | 3 | 2 | 1 |
| Нурлат муниципаль районы | 5 | 4 | 1 |
| Питрәч муниципаль районы | 3 | 2 | 1 |
| Балык Бистәсе муниципаль районы | 3 | 2 | 1 |
| Саба муниципаль районы | 3 | 2 | 1 |
| Сарман муниципаль районы | 3 | 2 | 1 |
| Спас муниципаль районы | 3 | 2 | 1 |
| Тәтеш муниципаль районы | 3 | 2 | 1 |
| Тукай муниципаль районы | 3 | 2 | 1 |
| Теләче муниципаль районы | 3 | 2 | 1 |
| Чирмешән муниципаль районы | 3 | 2 | 1 |
| Чистай муниципаль районы | 4 | 3 | 1 |
| Ютазы муниципаль районы | 3 | 2 | 1 |
| Яр Чаллы шәһәре | 19 | 15 | 4 |
| Казан шәһәре | 45 | 35 | 10 |
| Барысы | 211 | 154 | 57 |